| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 30.11.2016 г. Казань № 10-25/кс

2017 – 2019 елларга “Генерирующая компания” ачык ационерлык җәмгыятенең филиалы – “Балкыш” санаторий-профилакторие өчен ташландык суларны транспортировкалауга тарифлар билгеләү турында

“Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында” 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, “Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында” 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, “Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны исәпләп чыгару буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында” тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 27 декабрендәге № 1746-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “Генерирующая компания” ачык ационерлык җәмгыятенең филиалы – “Балкыш” санаторий-профилакторие өчен ташландык суларны транспортировкалауга тарифларны әлеге карарның кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2017 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. 2017 – 2019 елларга салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы “Генерирующая компания” ачык ационерлык җәмгыятенең филиалы – “Балкыш” санаторий-профилакторие өчен ташландык суларны транспортировкалауга тарифларының озак сроклы җайга салу параметрларын әлеге карарның 2 кушымтасына нигезләнеп билгеләргә.

4. Әлеге карар кушымтасында күрсәтелгән салкын су белән тәэмин итүче һәм су бүлүне башкаручы оешмаларга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына

тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты 2016 елның 30 ноябрендәге 10-25/кс санлы карарына 1 кушымта

# 2017 – 2019 елларга календарь чорларына бүлеп салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы “Генерирующая компания” ачык ационерлык җәмгыятенең филиалы – “Балкыш” санаторий-профилакторие өчен ташландык суларны транспортировкалауга тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы оешма | Ташландык суларны транспортировкалауга тарифлар (бер ставкалы), сум/куб.метр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 ел | | 2018 ел | | 2019 ел | |
| | | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр | 01.01.2018 алып 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 алып 31.12.2018 кадәр | 01.01.2019 алып 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 алып 31.12.2019 кадәр |
| | “Казан шәһәре” муниципаль берәмлеге | | | | | | |
| 1 | “Генерирующая компания” ачык акционерлык җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | “Генерирующая компания” ачык ационерлык җәмгыятенең филиалы – “Балкыш” санаторий-профилакторие (тарифлар НДСны исәпкә алмыйча күрсәтелгән) | 10,26 | 10,69 | 10,67 | 10,67 | 10,67 | 11,08 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
Дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты 2016 елның
30 ноябрендәге 10-25/кс санлы
карарына 2 кушымта

2017-2019 елларга салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы “Генерирующая компания” ачык ационерлык җәмгыятенең филиалы – “Балкыш” санаторий-профилакторие өчен ташландык суларны транспортировкалауга тарифларны озак вакытка исәпләнгән җайга салу параметрлары

| № п/п | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы оешма | Ел | Операцион чыгымнарның нигез дәрәҗәсе | Операцион чыгымнарның нәтиҗәлелек индексы | Табышларның норматив дәрәҗәсе | Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма чыгымы |
| | | | мең сум. | % | % | % | кВт·сәг./куб.м |
| 1 | “Генерирующая компания” ачык акционерлык җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | “Генерирующая компания” ачык ационерлык җәмгыятенең филиалы – “Балкыш” санаторий-профилакторие | | | | | | |
| 1.1.1 | Ташландык суларны транспортировкалау | 2017 | 161,83 | 1 | - | - | 0,33 |
| | | 2018 | 166,62 | 1 | - | - | 0,33 |
| | | 2019 | 171,55 | 1 | - | - | 0,33 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
Дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге